**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының**
**Поповка авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**№ 24** **«05» апрель 2021 ел**

**«Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Поповка авыл җирлеге муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыру тәртибе һәм шартлары турында нигезләмәне раслау хакында» 2020 елның 29 декабрендәге 16 номерлы Зәй муниципаль районының Поповка авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Зәй муниципаль районының Поповка авыл җирлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Поповка авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Поповка авыл җирлеге муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыру тәртибе һәм шартлары турында нигезләмәне раслау хакында» 2020 елның 29 декабрендәге 16 номерлы Зәй муниципаль районының Поповка авыл җирлеге Советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 4.16 пунктта:

а) икенче абзацта «күрсәтелгән мөлкәтне» сүзләрен «күрсәтелгән карарны» сүзләре белән алмаштырырга;

б) 17 абзацны үз көчен югалткан дип таныргa;

в) 19 абзацны үз көчен югалткан дип таныргa;

1.2. 4.20 пунктта «4.5.6. пункт белән» сүзләрен «әлеге нигезләмәнең 4.19 пункты белән» сүзләренә алмаштырырга;

1.3. 8.3 пунктның 4 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«-электр, элемтә һәм үткәргеч торба линияләрен, кайнар су белән тәэмин итүнең үзәкләштерелгән системаларын, салкын су белән тәэмин итү һәм (яисә) юынтык суларны чыгару линияләрен, системалар һәм мелиорация линияләрен салуны һәм алардан файдалану мөмкинлеген тәэмин итәргә.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU), җирлек торак пунктлары территориясендәге махсус мәгълүмат стендларында һәм Зәй муниципаль

районы рәсми сайтының «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштырырга.

3. Карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Совет рәисе И.Ә.Әмирханов